ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 декабарь, 2015 ел № 4/14

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының даими комиссияләре турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламенты нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/8 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының даими комиссияләре турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 маддәнең өченче абзацына «Шәһәр Хакиме» сүзләреннән соң «, Шәһәр Советы Президиумы» сүзләрен өстәргә;

2) 10, 11, 12, 13, 14 маддәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«10 маддә.**

Социаль-икътисадый үсеш һәм бюджет мәсьәләләре буенча даими комиссия Шәһәр Советы карамагында булган сорауларны түбәндәге юнәлешләр буенча алдан карый һәм әзерли:

- шәһәрнең комплексလы социаль-икътисадый үсеш планнарын һәм программаларын кабул итү һәм үтәлешен оештыру;
- шәһәр бюджеты проектын карау, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шәһәр бюджетын раслау, үтәлешен контрольдә тоту, шәһәр бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау;
- икътисадның муниципаль секторын үстерү;
- шәһәрнең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм кире кагу;
- муниципаль милектә булган милек белән идарә итү, файдалану һәм эш йөртү тәртибен һәм шартларын билгеләү;
- җирле салымнарны түләү буенча ташламалар бирү;

- муниципаль предприятиеләрне һәи учреждениеләрне төзү, үзгәтртеп төзү һәм ликвидацияләү;
- муниципаль милекне хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү;
- муниципаль милек реестрын алып бару тәртибен билгеләү;
- шәһәр җирләре һәм муниципаль милек белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибен билгеләү;
- товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыруны формалаштыру, башкару һәм контрольдә тоту тәртибен билгеләү;
- авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү;
- социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән коммерциясез оешмаларга, хәйрия эшчәнлегенә һәм ирекле ярдәмгә булышлык күрсәтү.

Даими комиссия Шәһәр Советы карамагындагы башка сорауларны карый.

**11 маддә.**

Шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссия Шәһәр Советы карамагында булган сорауларны түбәндәге юнәлешләр буенча алдан карый һәм әзерли:

- шәһәрнең генераль планын раслау, шул исәптән аңа үзгәрешләр кертү;
- җирдән файдалану һәм шәһәрдә төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау;
- шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү һәм раслау тәртибен билгеләү;
- шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;
- урам-юл челтәре элементларына, шәһәрнең планлаштыру элементларына атамалар бирү, мондый атамаларны үзгәртү, гамәлдән чыгару;
- биналарны һәм корылмаларны карау тәртибен билгеләү;
- шәһәр чикләрендә тирә-юнь мохитне саклау буенча чаралар оештыру;
- шәһәр урманнарыннан, шәһәр чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигый территория урманнарыннан файдалану, аларны саклау, яңадан үстерү;
- муниципаль берәмлек территориясе чикләрендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру тәртибен билгеләү;
- муниципаль берәмлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итүне, су агызуны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;
- коммуналь комплекс оешмалары хезмәтләренә һәм товарларына тарифларны көйләү тәртибен билгеләү;
- ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

- шәһәр чикләрендә җирле билгеләнештәге автомобиль юллары мөнәсәбәтендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру, парковкалар (парковка урыннары) төзү һәм эшләвен тәэмин итү;

- җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү;

- дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм җирле билгеләнештәге курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү;

- җирле билгеләнештәге аеруча саклана торган табигый территорияләрдән файдалану һәм саклау өлкәсендә муниципаль конторольне гамәлгә ашыру;

- каты көнкүреш калдыкларын җыю (шул исәптән аерып җыю), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;

- су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру;

-гомуми кулланыштагы су объектларынан файдалану кагыйдәләрен билгеләү.

Даими комиссия Шәһәр Советы карамагындагы башка сорауларны карый.

**12 маддә.**

Регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссия Шәһәр Советы карамагында булган сорауларны түбәндәге юнәлешләр буенча алдан карый һәм әзерли:

- Шәһәр Советы депутаты статусын билгеләү;

- Шәһәр Советы депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

- Шәһәр Советы даими комиссияләрен оештыру, бетерү, даими комиссияләр составына үзгәрешләр кертү;

- Шәһәр Советы Регламенты;

- шәһәр чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм ликвидацияләү;

- шәһәрдә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- шәһәр территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

- шәһәр территориясендә һәлаккәттән саклау хезмәтен һәм (яки) һәлаккәттән саклау формированиеләрен төзү, карап тоту һәм эшчәнлеген оештыру;

- шәһәр муниципаль предприятиеләренең һәм учреждениеләренең мобилизацион хәзерлеге буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- шәһәр чикләрендә террорчылык һәм экстремизм күренешләрен профилактикалау һәм (яки) террорчылык һәм экстремизм күренешләре китереп чыгарган нәтиҗәләрне бетерү;

- территориаль оборона һәм гражданлык оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәти тыш хәлләрдән халыкны һәм шәһәр территориясен саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашкан гражданнрага һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү;

- халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;

- муниципаль берәмлек Уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, үтәлешен контрольдә тоту;
- гражданнарның хокукый инициативасы;
- муниципаль хезмәт;
- территориаль иҗтимагый үзидарә;
- социаль әһәмиятле эш төрләрен билгеләү;
- шәһәрнең тантаналы һәм истәлекле даталарын билгеләү;
- шәһәр исемнәрен һәм бүләкләрен булдыру, аларны бирү тәртибе;
- муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору;
- җирле референдумны, муниципаль сайлауларны билгеләү һәм үткәрү;
- гавами тыңлаулар, сорашулар, җыелышлыр, гражданнар конференцияләрен уздыру;
- җирле үзидарә органнарының ТР муниципаль берәмлекләре Советын һәм муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрен оештыруда һәм аларның эшендә катнашу тәртибен билгеләү;
- Шәһәр Советы депутатлары тарафыннан этика кагыйдәләрен үтәү.

Даими комиссия Шәһәр Советы карамагындагы башка сорауларны карый.

**13 маддә.**

Гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм социаль яклау мәсьәләләре буенча даими комиссия Шәһәр Советы карамагында булган сорауларны түбәндәге юнәлешләр буенча алдан карый һәм әзерли:

- социаль найм килешүләрен төзү шартларын һәм тәртибен билгеләү;
- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак бүлмәләр белән тәэмин итү;
- шәһәр халкын элемтә хезмәте, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;
- гражданнарга медицина ярдәмен бушлай күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасы нигезендә шәһәр территориясендә халыкка медицина ярдәме күрсәтү өчен шартар тудыру;
- медицина оешмаларында эшләү өчен, медицина хезмәткәрләрен һәм фармацевтика хезмәткәрләрен җәлеп итү максатларында, уңайлы шартлар тудыру;
- муниципаль сәламәтлек саклау системасы учреждениеләрен үстерү, аларның эшчәнлек характерын һәм күләмен билгеләү;
- халыкның мәшгульлеге;
- гаилә, ана һәм балачак.

Даими комиссия Шәһәр Советы карамагындагы башка сорауларны карый.

**14 маддә.**

Мәгариф, мәдәният, милли мәсьәләләр, яшьләр эшләре һәм спорт буенча даими комиссия Шәһәр Советы карамагында булган сорауларны түбәндәге юнәлешләр буенча алдан карый һәм әзерли:

- муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем укый алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, гомуми урта белем бирүне оештыру;

- шәһәр территориясендә балаларга өстәмә белем бирүне һәм һәркем укый алырлык мәктәпкәчә түләүсез белем бирүне оештыру;

- муниципаль мәгариф оешмаларында балаларны карауны һәм тәрбияләүне тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

- каникул вакытында балаларның ялын оештыру;

- яшьләр сәясәте;

- шәһәрдә балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

- ял итү өчен шартлар тудыру һәм шәһәр халкын мәдәният оешмалары хезмәте белән тәэмин итү;

- шәһәр халкына массакүләм ял өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру;

- шәһәр халкына китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру;

- шәһәрдә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартларны тәэмин итү, шәһәрнең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру;

- шәһәр территориясендә җирле традицион халык сәнгать иҗатын үстерү, халыкның иҗади кәсепләрен саклау, торгызу һәм үстерү өчен шартлар тудыру;

- мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру;

Даими комиссия Шәһәр Советы карамагындагы башка сорауларны карый.»;

3) 31 матдәнең бишенче абзацында «уртак утырыш беркетмәләре» сүзләрен «уртак утырыш беркетмәсе» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе, законлылык һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме — Н.Г. Мәһдиев